*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

№6 (67)

Март, 2025 нче ел




**2025 ел - Ватанны саклаучылар елы**

***"Укытучы кулында гади чәчәкләр генә түгел, тормыш чәчәкләре – сабый балалар".***

***Габдрахман Әпсәләмов***

**Бу санда**

*"Беренче адымнар" исемле фәнни-гамәли конференциясе* 2

*Республика күләмендә фән олимпиадалары дәвам итә* 2

*Нәтиҗәләр киләчәкне билгели* 3

*Һөнәр сайлау - бик җаваплы адым* 3

*Укучылар каләм тибрәтә, һөнәрләр дөньясында йөзә* 4

*Гимназия яңалыклары -*
*рәсми сайтта*
*https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym*

*Гимназия яңалыклары -*
*социаль челтәрдә*
*https://vk.com/gymnasiummus*

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### «Яшь мастер» төбәкара балалар чемпионаты







15 мартта Татарстан Республикасында «Яшь мастер» төбәкара балалар чемпионатының VI төбәк этабы узды. Анда районыбызның башлангыч сыйныф укучылары һәм балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр катнашты.

Конкурс йомгаклары буенча 2 нче а сыйныфы укучылары - Гыймранов Дамир «Лаборатор химик анализ" компетенциясе буенча "Химик анализның иң тырыш лаборанты" номинациясендә, Микаелян Арман «Кондитер эше» компетенциясендә «Иң пөхтә кондитер» номинациясендә җиңү яуладылар.

Укучыларның остазы - башлангыч сыйныф укытучысы Ләйсән Мортазина.

### "Кызыл, сары, яшел!" агитбригадалар конкурсы




Мөслим гимназиясе базасында башлангыч сыйныф укучылары арасында "Кызыл, сары, яшел!" исеме астында балалар юл-транспорт травмасын профилактикалау буенча ярышлар үтте.

"Мөслим гимназиясенең 4 нче а сыйныфы командасы икенче урынга лаек булды.

Агитбригада командасы җитәкчесе - Галия Әюпова.

### Пушкин укулары



Яр Чаллы шәһәрендә "Пушкин укулары" Бөтенроссия ачык иҗат бәйгесе узды. Мөслим гимназиясе укучылары Солтанов Рияз, Кашапова Зилә, Ямалова Динә һәм Кашапов Азамат беренче дәрәҗә дипломнарга лаек булдылар (җитәкчеләре Хәйруллина Ч.А.). Шулай ук 9 нчы сыйныф укучылары (җитәкчеләре Галиева И.Т.) беренче дәрәҗә Дипломга ия булдылар.

## "БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР" ИСЕМЛЕ ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ




Сарман районында башлангыч сыйныф укучылары арасында "Беренче адымнар" исемле фәнни-гамәли конференция узды.

"Бөек шәхесләрне өйрәнәбез" секциясендә балалар шагыйре Мөҗәһит Әхмәтҗанов иҗатын өйрәнеп, Ралия Сәләхова җиңүче булды.

"Гаилә һәм гаилә кыйммәтләре" секциясендә Азалия Бәширова гаилә фермалары турында сөйләп җиңү яулады.

"Бөек Җиңүгә - 80 ел" секциясендә Раяна Идиятуллина бабасы - Бөек Ватан сугышы ветераны Александр Кондратьев белән таныштырды һәм лауреат булды.

Укучыларның фәнни җитәкчесе - сыйныф җитәкчеләре Ләйсән Фәхертдинова.

Котлыйбыз һәм иҗади уңышлар телибез!

## РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘ ФӘН ОЛИМПИАДАЛАРЫ ДӘВАМ ИТӘ

***Февраль-март айларында да республика, бөтенрәсәй фән олимпиадалары төрле фәннәрдән үтте. Бүген безнең 23 призлы урыныбыз бар.***

Нәтиҗәләргә ирешү укытучыларыбызның тынгысыз хезмәте, укучыларыбызның тырышлыгы. Бөтенрәсәй олимпиадасының регион этабы призерлары: рус әдәбияты буенча **Айгильдина Зарина** (8 нче в сыйныфы), **Габидуллина Азалия** (10 нчы сыйныф), кызларның укытучылары Хәйруллина Ч.А., Галиева И.Т. Татар мәктәпләрендә белем алучы укучылар арасында узган туган (татар) тел республика олимпиадасында 10 нчы сыйныф укучысы **Хәсәнова Йолдыз** (укытучысы - Мирзаморатова Г.М.) һәм **Солтанова Аделина** (укытучысы – Ямалова Г.Ф.) призлы урын яуладылар. **Шәрифуллин Рәфил** (укытучысы – Галиев З.З) Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре фәненнән призер, рус төркемнәрендә үткәрелүче татар теле фәне призеры **Асманова Ирина** (укытучысы – Ямалова Г.Ф.), рус мәктәпләренең татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен үткәрелгән татар әдәбияты буенча республика олимпиадасы призеры 10 нчы сыйныф укучысы **Газетдинова Аделя** (укытучысы - Мирзаморатова Г.М.).

***Призерларны һәм аларга белем бирүче мөгаллимнәребезне чын күңелдән тәбрик итәбез!***




Газетдинова Аделя



Хәсәнова Йолдыз
Солтанова Аделина



Габидуллина Азалия



Айгильдина Зарина



Шәрифуллин Рәфил



Асманова Ирина

# НӘТИҖӘЛӘР КИЛӘЧӘКНЕ БИЛГЕЛИ



**2022 нче ел -**

***Шамил Баянов***

*Химия -100*
*Биология –100*

*Санкт-Петербург дәүләт медицина университеты студенты*



**2023 нче ел –**

***Лиана Исмәгыйлова***

*Химия -100*
*Биология –100*

*Казан дәүләт медицина университеты студенты*



**2024 нче ел –**

***Илина Бариева***

*Химия -100*

*Н.И.Пирогов ис. Рәсәй милли тикшеренү медицина университеты студенты*

Мөслим гимназиясе үзенең ишекләрен 2003 нче елда ача. Гимназиядә һәр яктан камил шәхес тәрбияләүгә зур игътибар бирелә. Чыгарылыш укучылары югары уку йортларына кереп белем алуларын дәвам итәләр. Алар арасында табиблар, педагоглар, фән һәм мәдәният эшлеклеләре бар.

Эш дәверендә гимназия югары күрсәткечләргә иреште. Ел саен укучыларыбыз район, шәһәр, республикакүләм, рәсәйкүләм, халыкара бәйгеләрдә, олимпиадаларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашып, призлы урыннар яулыйлар.

Уку йорты эшчәнлеге бала тормышының аерылгысыз өлеше. Бала гимназиядә вакыт үткәрми, бала гимназиядә яши.

Укучыларның югары балларга БДИ тапшырулары моның нәтиҗәсе булып тора. Ел саен мәктәпне медальга тәмамлаучылар саны да арта бара.

2022 нче елдан башлап ЕГЭны 100, 200 баллга тапшыручы укучыларыбыз бар.

2022 нче елда – Баянов Шамил, химия һәм биология фәненнән, 2023 нче елда Исмәгыйлова Лиана, шулай ук биология, химия фәннәреннән, 2024 нче елда Бариева Илина химия фәненнән ЕГЭларны 100 баллга тапшырдылар. Укучыларны әзерләүдә укытучыларның өлеше гаять зур. Укытучыларыбыз һәммәсе дә үз фәненә тугры. Укучыларның уңышлары нигезендә, педагогның тынгысыз хезмәте ята.


2023 нче елны медицина сыйныфлары ачылу да зур сөенеч булды, бу сыйныфларда укучы егет-кызлар Казан дәүләт медицина университеты һәм Әлмәт медицина көллияте укытучылары үткәргән дәресләрне көтеп алалар.

Безнең гимназиянең миссиясе - укучыларның мөмкинлекләрен, белем алуга омтылышларын исәпкә алып, үсеш өчен шартлар тудыру. Мәктәп укучылары алган белем бүген һәм киләчәктә аларның тормышта үз юлларын табуда ярдәм итәргә тиеш.

Соңгы биш елда укучыларның гимназияне уңышлы гына тәмамлап югары уку йортларына, техникум, колледжларның түләүсез бүлекләренә уңышлы гына керүләре, үсеш күзәтелә. Аеруча медицина, юридик, психология, техник юнәлеш сайлаучы укучыларыбыз күп.

***Лира Заялова,***
***гимназиянең уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***

# ҺӨНӘР САЙЛАУ - БИК ҖАВАПЛЫ АДЫМ



**Профориентация - яшьләрне ирекле, аңлы һәм мөстәкыйль һөнәр сайлауга әзерләүнең фәнни нигезләнгән системасы.** Ул һәр шәхеснең индивидуаль үзенчәлекләрен дә, хезмәт ресурсларын җәмгыять мәнфәгатьләрендә тулысынча бүлү кирәклеген дә исәпкә алырга тиеш. Нәкъ менә шуңа күрә мәгариф системасы алдына яңа проблема килеп баса - үсеп килүче буынга карарларны мөстәкыйль кабул итү һәм җаваплы гамәлләргә, һөнәри эшчәнлеккә югары мәгълүмати тирәлектә әзерләү. Һөнәр дөньясы күптөрле һәм үзгәрүчән, яңа һөнәрләр барлыкка килә. Һәр кеше тормышында кайда белем алуны дәвам итәргә яки кая эшләргә керәклеген хәл итәргә, ягъни һөнәр сайларга, үз тормыш юлын сайларга туры килү мизгеле җитә.

***Психолог киңәшләре:***

- Тормышта үз юлыңны, үз һөнәреңне табу бик җитди мәсьәлә, ялгышлык ясау кыйммәткә төшәргә мөмкин. Күңеленә ятмаган һөнәр сайлаган кешенең укуы да, эше дә шул чама гына, ул бернинди рәхәтлек китерми.

- Мәктәпнең чыгарылыш сыйныф укучысы кем булачагын, нинди һөнәр сайлаячагын үзе өчен алдан ук билгеләгән булса, бу бик яхшы. Чыгарылыш сыйныф укучыларының күбесе уку йортларын башкаларга ияреп яки әти-әни киңәше белән, я булмаса җыелган баллар мөмкинлегеннән чыгып сайлый. Андыйларга нәрсә киңәш итәргә соң?

Мәсәлән, Америкада: мәктәпне тәмамлаганнан соң, балалар башта волонтерлар булып эшли, коллективта аралашу тәҗрибәсе туплый, эш бирүченең рекомендациясен ала. Бер үк вакытта, үзлегеннән укыйлар, кызыксыналар, университетлар тәкъдимен өйрәнәләр, физик һәм рухи үсәләр, шулчакта гына кеше үзенә хас, теләгенә һәм мөмкинлекләренә туры килгән дөрес һөнәрне сайлый.

- Әгәр ул үзе хыялланган уку йортына барырга тели икән, өстәмә имтихан бирүдән курыкмаска тиеш. Аны тапшыру өчен ул бар тырышлыгын куячак. Ә инде аны әйбәт тапшырачагына икеләнә икән, сүз дә юк, кулдагы чыпчык яхшырак.

- Хыялыгызның тормышка ашачагына ышаныгыз, моның өчен барсын да эшләгез! Тормыш тудырган кыенлык-киртәләрне җиңәргә үзегездә көч, үҗәтлек тапмыйсыз икән, киңәшнең файдасы да юк.

- Үз язмышың өчен җаваплылык хисе нәкъ менә 17-18 яшьләрдә туа. Әмма бу чорда әти-әнигә бәйлелек (территориаль, финанс, психологик) була әле. Күпләр язмышы өчен җаваплылыкны үз өстенә алудан курка, әти-әни таләбеннән чыга алмый.

***Кашапова Айсылу,***
***гимназия психологы***

# УКУЧЫЛАР КАЛӘМ ТИБРӘТӘ, ҺӨНӘРЛӘР ДӨНЬЯСЫНДА ЙӨЗӘ

*Мөслим гимназиясе укучылары иҗаты*

## Минем булачак һөнәрем



Мин киләчәктә теш табибы булырга телим. Стоматология – тешләр, авыз куышлыгы белән бәйле медицина тармагы. Әлеге һөнәр кешеләрнең сәламәтлеген сакларга мөмкинлек бирә.

Теш табибы булуның күп өстенлекләре бар. Беренчедән, алар кешеләргә тешләрен дәвалап, сәламәтлекләрен ныгытырга ярдәм итәләр. Күп кеше теш авыртуы белән газаплана, теш табибы аларга ярдәм күрсәтүчеләрдән беренче булып тора.

Икенчедән, стоматология – даими үсештә булган фән. Яңа технологияләр, материаллар һәрвакыт барлыкка килә. Теш табибы буларак, мин гел үз белемемне арттырырга һәм һөнәри үсештә булырга тырышачакмын. Бу миңа үз эшемне яхшырту һәм пациентларыма иң яхшы нәтиҗә күрсәтергә ярдәм итәчәк.

Өченчедән, теш табибы булып эшләү мине иҗади яктан да җәлеп итә. Тешләрне дәвалау гына түгел, аларның формасының, төсенең һәм гомумән, авыз куышлыгының матурлыгы игътибарга алынырга тиеш.

Теш табибы минем өчен мөһим һәм җаваплы һөнәр. Киләчәктә теш табибы булу хыялын тормышка ашыру өчен мин медицина университетына укырга керергә телим. Минем хыялым – яхшы табиб булып, кешеләргә ярдәм кулы сузу һәм аларның елмаюын күрү!

***Галимова Айназ,***
***8 нче б сыйныфы укучысы***

***

Минем хыялым – биюче булу. Бию – тормышның бер өлеше, ул миңа шатлык, ирек һәм иҗади мөмкинлекләр китерә. Биюче булу – хисләреңне һәм эмоцияләреңне башкаларга җиткерү.



Бию белән кечкенәдән кызыксына башладым, һәрвакыт телевизордан бию программаларын карарга яраттым. Биючеләрнең хәрәкәтләре, аларның энергиясе мине әсир итте. Алар кебек матур һәм синхрон рәвештә биисем килә.

Бию – ул физик активлык кына түгел, ул шулай ук иҗат. Минем өчен бию – үземне ирекле тоту, хисләремне белдерү һәм башкалар белән уртакашу. Бию аша мин дөньяны башкача күрә алам. Ул миңа бәхет, тынычлык һәм иҗади энергия бирә, бу хыялымны чынга ашырырга тырышам!

***Мадьярова Мәрьям,***
***8 нче б сыйныфы укучысы***

***

Минем булачак һөнәрем – тәрбияче. Кем булырга теләвем турында озак уйладым, әмма нәтиҗәдә балалар белән эшләргә теләвемне аңладым.



Балаларны яратам, үземнең энеләрем һәм сеңлеләрем бар, аларны карыйм. Миңа балаларга ни өчен кулларны юарга яки киемнәрне ничек кияргә кирәклеген, ни өчен уенчыкларны плитәгә куярга яки эшләрдән качарга ярамавын аңлату ошый. Укучылар боларның барысын да белә инде, ә менә кечкенәләр юк, шуңа күрә, нәкъ менә алар белән эшләргә телим.

Тәрбияче эше – балалар белән уен уйнау гына түгел, аның үз авырлыклары бар. Мәсәлән, аналар белән тату яшәргә өйрәнергә, яки спектакльләр куярга, яки бик игътибарлы булырга кирәк, чөнки өч баланы түгел, ә утыз баланы тәрбияләргә туры килә.

Тәрбияче һөнәре ошый һәм мин барысын да булдырырмын дип өметләнәм.

***Зулунова Ирода,***
***8 нче в сыйныфы укучысы.***

***



Һәр кешенең тормышында һөнәр сайлау вакыты җитә. Бу җаваплы адым, аны һәркем үзе эшләргә тиеш. Мин, мәсәлән, юрист булырга телим. Җәмгыятьтә юристларның роле әһәмиятле, кеше тормышы белән бәйле булырга мөмкин. Юрист белемле булырга, барлык законнарны белергә һәм даими камилләшергә, белемнәрен тулыландырырга тиеш.

Юрист һөнәре гаделсез вәзгыятьне ачыкларга, гаепсез кешеләргә ярдәм итәргә мөмкинлек бирә. Бу һөнәр куркыныч та булырга мөмкин, гаделлек артыннан кууда кешенең дошманнары барлыкка килергә мөмкин. Әмма кешеләргә ярдәм итү һәм дөньяны бераз гына булса да яхшырак итү теләге барлык куркуларны юкка чыгара.

Язмамны тәмамлап шуны әйтәсем килә: кыенлыклардан курыкмаска һәм куркуларыңа сине җиңәргә ирек бирмәскә кирәк. Һөнәр сайлаганда хаталар ясаудан куркырга кирәкми. Егерме беренче гасырда мөмкинлекләр шулкадәр күп, син теләсә кайсы һөнәргә укып, үзеңә ошаган белгечлек буенча эшли аласың.

***Замалова Зәринә,***
***8 нче в сыйныфы укучысы***

Дәвамы

ТЫЛСЫМ+
Март, 2025 нче ел
№6 (67)
Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Замалова Зәринә
**Корректорлар:** Хәйруллина Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Фәхрәзиева Алинә
**Дизайнер:** Мостафина Рәйлә
**Компьютерда җыючылар:** Вагыйзов Айзат, Сәләмов Наил

*2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә*
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100